**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2015 ел, 21 сентябрь № 693

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыручы коммерциягә карамаган Татарстан Республикасы оешмаларына дәүләт ярдәме күрсәтү турында» 2009 ел, 8 июнь, 373 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 28 декабрь, 890 нчы; 2010 ел 21 сентябрь, 749 нчы; 2011 ел, 29 июль, 606 нчы; 2012 ел, 9 июнь, 500 нче; 2013 ел, 28 июнь, 444 нче; 2014 ел, 5 июнь, 380 нче; 2014 ел, 8 октябрь, 734 нче; 2014 ел, 18 октябрь, 769 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсы турындагы нигезләмәдә:

4.2 нче пунктта «шулай ук дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр» сүзләрен «дәүләт учреждениеләре һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук коммерциягә карамаган оешмалар (аларга мөнәсәбәтле ябу яки үзгәртеп оештыру турында карар кабул ителгән)» сүзләренә алмаштырырга;

4.3 нче пунктта:

беренче абзацта «заявка» сүзен «бер социаль әһәмияткә ия булган проектны гамәлгә ашыруны планлаштыру турында бер заявка» сүзләренә алмаштырырга;

алтынчы абзацта «Заявка беркетелгән, аңа номер куелган һәм расланган булырга тиеш» сүзләрен «Заявка һәм аңа теркәлгән документлар беркетелгән, аларга номер куелган һәм расланган булырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 4.9 нчы пункт өстәргә:

«4.9. Конкурста катнашу өчен тапшырылган заявкалар рецензияләнми, кире кайтарылмый һәм Вәкаләтле органда билгеләнгән тәртиптә саклана.»;

10.2 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10.2. Грантлар социаль юнәлештәге коммерциягә карамаган оешмалар тарафыннан социаль проектларны тормышка ашыру өчен күздә тотылган барлык акчаларнын 20 процентыннан ким булмаган күләмдә аларны тормышка ашыруны, файдаланыла торган мөлкәтне һәм үз ихтыяры белән эшләүчеләрне акчалата бәяләүне, башка чыганаклардан максатчан акчалата керемнәрне кертеп финанслашу шартларында бирелә.»;

10.6 нчы пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Грант алучы Вәкаләтле орган һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы таләбе буенча, гранттан максатчан файдалануны тикшерү өчен, тотылган акчаларны раслаучы документларны (төп нөсхәләрен һәм/яки коммерциягә карамаган оешма тарафыннан расланган күчермәләрен) бирергә тиеш.»;

әлеге карар белән расланган Социаль әһәмияткә ия булган проектларны тормышка ашыруда катнашучы коммерциягә карамаган оешмалар өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты грантларын алуга республика конкурсын үткәрү буенча республика конкурс комиссиясе составында:

Сергей Альбертович Осипов вазыйфасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министрының беренче урынбасары»;

комиссия составыннан С.В.Гыйниятуллинаны чыгарырга;

комиссия составына Айдар Марат улы Каюмовны, Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры урынбасарын кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2015\693.doc